РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«26» август 2025ел

г. Альметьевск

**КАРАР**

№ 2130

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2023 елның 5 декабрендәге 7582 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны оештыруга һәм аларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларда кайнар туклануның уртача бәясеннән раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 апрелендәге 253 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 16 сентябрендәге 789 номерлы карары белән расланган «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативына үзгәреш кертү турында» 2025 елның 27 маендагы 362 номерлы карарлары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклландыруны оештыру турында» 2023 елның 5 декабрендәге 7582 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 22 февралендәге 726 номерлы, 2024 елның 19 ноябрендәге 3678 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Көненә бер укучыга ата-ана кертемнәре суммасын:

район гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныфлары укучылары 64 сум 47 тиен;

Зак. № 305-2000

район гомуми белем бирү учреждениеләренең озайтылган көн төркеменә йөрүче укучыларына өстәмә туклану 34 сум 95 тиен»;

карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Билгеләргә:

Район гомуми белем бирү учреждениеләренең 1-4 сыйныфларында укучылар өчен бер укучыга түләүсез балансплы туклану бәясе 74 сум 77 тиен;

район гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныфлары укучылары өчен бер укучыга балансплы кайнар туклану бәясе 74 сум 77 тиен;

районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә озайтылган көн төркеменә йөрүче укучыларны бер укучыга өстәмә тукландыру бәясе-34 сум 95 тиен.

Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең «1 нче лицей-интернат» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесендә (алга таба – 1 нче лицей – интернат) яшәп тәрбияләнүче бер укучыга балансплы кайнар туклану бәясе-көнгә 246 сум 42 тиен;

1 нче лицей-интернатта яшәүсез бер тәрбияләнүчегә балансплы кайнар туклану бәясе-көнгә 90 сум 70 тиен (төшке аш-74 сум 77 тиен; төшке аш-15 сум 93 тиен);

бер укучыга инвалид балалар өчен ике тапкыр балансплы түләүсез туклану бәясе көненә 109 сум 72 тиен, шулай ук ата-аналарның (законлы вәкилләренең) язма гаризасы буенча коры паек рәвешендә (белем алучы инвалид бала стационар (амбулатор) дәвалануда булган очраклардан тыш) ике тапкыр түләүсез туклану бирелә. Ике тапкыр Түләүсез туклануны һәм коры паекларны акчалата компенсациягә алмаштыру башкарылмый;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 16.09.2024 № 789 карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативына үзгәреш кертү турында» 2025 елның 27 маендагы 362 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә 2025 елның 31 декабренә кадәр бер укучыга көнгә 10 сум 30 тиен күләмендә туклану белән тәэмин итү. Балансплы туклану нормативы нигезендә аерма укучыларның ата-аналары исәбеннән түләнә»;

карарга 1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Укучыларны тукландыру 74 сум 77 тиенгә оештырыла.

Белем алучы инвалид балаларны тукландыру 109 сум 72 тиенгә оештырыла.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф. Мортазхинга йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы

А.М. Каюмов